# «Мәрхәмәт елмаюдан башлана»



**Уяндыңмы, елмай!**
**Көнне башла шулай,**
**Елмай үз-үзеңә,**
**Әйтәсе сүзеңә.**
**Таралыр бар кайгың,**
**Тыныч калыр җаның**
**Күтәр күңелеңне**
**Бу бәхет түгелме?**



# Нәрсә соң ул **мәрхәмәтлелек**?

**Мәрхәмәтлелек** – ул барлык яхшы эшләр, елмаюлы караш, кемгә дә булса булышу, ярдәм итү, хөрмәт һәм ихтирам.



# Ә начарлык нәрсә ул?

**Кешеләргә, хайваннарга, кошларга, табигатькә карата начар мөгамәлә.**



"Яхшылык күрәсең килсә, яхшылык ит" диелә татар халык мәкалендә. Ә сез бу мәкальне ничек аңлыйсыз?

Җавап:

- Кешеләргә эшләгән яхшылык сиңа яхшылык булып кайта.

- Ә ачулы, тар күңелле булу, башкаларның уңышыннан көнләшү бик начар гадәт. Шуңа күрә шәфкатьле, ярдәмчел булырга, бер-береңә матур, ягымлы сүзләр әйтеп, күңелләрне күтәрергә омтылырга кирәк.

# Мәкальләр

| | |
|---|---|
| Мәрхәмәтле сүз, | ә аның игелекле эшләре бизи. |
| Кешене кием түгел, | песи өчен дә әһәмиятле. |
| Көмеш белән мактанма, | шул бәхетле булыр. |
| Кем игелек эшли, | анда дөреслек тә аз. |
| Кемдә игелек юк, | игелек белән мактан. |
| Матурлыкны эзләмә- | игелек эзлә. |

# Яхшылык ит

Әйе, яхшылыкны кеше алдында мактану өчен эшләмиләр. Татар халкында яхшылык ит тә, диңгезгә ташла, балык белер, балык белмәсә халык белер” – дигән әйтем бар. Сез дә бу теләкләрне исегездә калдырыгыз, һәр көнне игелекле гамәлләр кылырга, изге эшләр башкарырга, кешеләргә миһербанлы, шәфкатьле булырга тырышыгыз.

**Бәхетле бала.**
**Бәхетле шул баладыр,**
**кайсы дәресенә күңел бирсә,**
**Мөгаллимне олуг күрсә,**
**белергә кушканын белсә,**
**Сабакка калмаса соңга,**
**борылмый барса уң-сулга,**
**Уенга салмаса ихлас—**
**менә бәхете аның шунда.**
***Кешеләргә итеп шәфкать,***
***үзеннән зурга юл бирсә,***
***Бәхетсезләрне кимсетми,***
***егылганнарга кул бирсә.***
***(Г. Тукай)***

**“Тирә-ягыбызда караучысыз калган өлкәннәр, инвалидлар, ятимнәр, авыр хәлләргә очраган кешеләр бар. Алар безнең ярдәмгә мохтаҗ. Аларга ярдәм кулы сузу, игелек кылу—әхлакый бурычыбыз. Бер-беребезне кайгыртып яшик, бер-беребезгә игътибарлы һәм ихтирамлы булыйк” М. Ш. Шәймиев.**

# Һәр көн игелек кыл!



# Тест «Мәрхәмәтлеме, мин?"



# Җаваплар бланкы

| Сораунын № | 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|---|
| Җавап | | | | |
| Баллар | 1 | 2 | 2 | 1 |

# Тест «Мәрхәмәтлеме, мин?»

1. **Синең акчаларың барлыкка килде. Бөтен булган акчаңны дусларыңа яки туганнарыңа бүләк алыр өчен бетерер идеңме?**
2. **Иптәшең белән сөйләшкәндә ул сиңа үзенең проблемалары турында сөйли ди. Әгәр дә бу тема сиңа кызык булмаса, син моны иптәшеңә әйтәчәксеңме?**
3. **Әгәр дә син уенда җиңелгәнең күренеп тора икән, син уенны уйнап бетерәчәксеңме?**
4. **Әтиең яки әниең сиңа берәр эш кушса, ә син копьютерда дустың белән кызык бер уен уйныйсың ди, син әти-әниеңнең сүзен тыңлыячаксыңмы?**

# Нәтиҗәләр:

- 5 очкодан күбрәк: Син әйләнә-тирәндәге кешеләргә ошыйсың, кешеләр белән аралаша беләсең.Дусларың күп. Бер кимчелек:беркайчан да беркемгә дә үзеңнең мәрхәмәтлелегең белән эш итәргә рөхсәт итмә.
- 4 тән 6:Синең мәрхәмәтлелегең – вакыйгаларга бәйле, син һәркем белән дә мәрхәмәтле түгел. Кем өчендер син барысын да эшлисең, ләкин һәрнәрсәдә һәм һәркем белән тигез булырга телисең.
- 5 очкодан әз:Сиңа үзең белән шөгыльләнергә кирәк.





# Мәрхәмәтле бул!







***<u>Һич яхшылык эшли алмасаң  син</u>***
***<u>Кешеләргә бик-бик теләп тә, -</u>***
***<u>Яхшы теләк телә,</u>***
***<u>Ул да кайчак</u>***
***<u>Зур көч өстәп куя йөрәккә.</u>***